ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная,19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 декабрь 2022 ел** **№ 11**

**Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.12.2019 ел, 75 нче санлы “Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хәрби исәп-хисап алып баручы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында” карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Оборона министрының "Россия Федерациясе хәрби частьләре һәм Кораллы Көчләре оешмаларының граждан персоналына хезмәт хакы күләмнәрен арттыру турында" гы 2022 елның 30 сентябрендәге 587 номерлы боерыгы нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү системасын камилләштерү максатларында Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 1 октябреннән Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.12.2019 ел, 75 нче санлы “Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитетының бердәм тариф челтәре кагылмый торган баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, хәрби исәп-хисап алып баручы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында” карары белән расланган «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең, Алан-Бәксәр авылы авылы башкарма комитетының хәрби исәп-хисап алып баручы хезмәткәрләренең хезмәт окладлары күләмен 1,04 тапкыр арттырырга (30.09.2020ел, 26 нчы санлы карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпеә алырга).
2. “Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авылы авылы башкарма комитетының хәрби исәп-хисап алып баручы хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәтенә түләүне оештыру турында” Нигезләмәсенең 2 кушымтасында 2 абзацта “6552” санын “6815» санына алыштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземнән калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Алан-Бәксәр авыл җирлеге З.Р.Гарифуллина